Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Аппак авыл Советы

КАРАРЫ

16 февраль 2026 ел                                                                 № 12

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы « Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмә хакында»гы 2025 елның 29 гыйнварындагы 117 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә

Аппак авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы « Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмә хакында»гы 2025 елның 29 гыйнварындагы 117 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җирлектә бюджет процессын мәгълүмати тәэмин итү РФ БК таләпләре нигезендә дәүләт һәм муниципаль (иҗтимагый) финанслар белән идарә итү өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан файдалану юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

1.2. 24 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль программалар агымдагы финанс елының 1 февраленнән дә соңга калмыйча җирлек Советының җирлек бюджеты турындагы карарына туры китерелергә тиеш.»;

1.3. 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«Агымдагы финанс елында бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирүне таләп итүче суд актларын (затларга китерелгән зыянны компенсацияләү максатларында чыгарылган суд актларыннан тыш) үтәү чыгымнарның суд актында билгеләнгән максатларга туры килә торган статьялары буенча җирлек бюджеты турындагы карарда каралган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

1.4. 32 статьяның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанс органы касса планын төзү һәм алып бару тәртибен, шулай ук бюджет акчаларын баш урнаштыручылар, бюджет керемнәренең баш

администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары тарафыннан касса планын төзү һәм алып бару өчен кирәкле белешмәләрне формалаштыру, тапшыру тәртибен, составын һәм вакытларын билгели.».

1.5. 35 статьяның 4 пунктында «,Татарстан Республикасы законнары, җирлек Советы карарлары»сүзләрен өстәргә.;

1.6. 35 статьяның 5 пунктында «, Татарстан Республикасы законнары, җирлек Советы карарлары»сүзләрен өстәргә.;

2. Әлеге карарны Аппак авылы, Тынычлык урамы, 71 йорт; Илтән-Бота авылы, Совет урамы, 71 нче йорт торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга .

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Нигезләмәнең 1 пункты 1.2 пунктчасы 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Аппак авыл
җирлеге башлыгы В.Н. Горбунова